# Сүзләргә сорау куй, сүз төркемнәрен ата

Ипи- ?

Җылы - ?

Шатлана - ?

Алар - ?

Имән - ?

Ничек - ?

Аз - ?

Төлкедәй - ?

Җидешәр - ?

Татарча - ?

Зәңгәр - ?


Бу - ?

Булышырга - ?


Ике - ?

Мияу - ?

Микикики - ?



Ни өчен?







Тавыш - физик күренеш, ул механик тирбәлешләр рәвешендә тарала.Амплитуда һәм ешлык белән характерлана. Амплитуда тавышның яңгыравык булуын характерлый. Ешлык тон, биеклекне билгели.




# Аваз ияртемнәре



Кеше тавышына, хайван һәм кош-корт, бөҗәкләр чыгарган авазларга, һәм төрле җансыз предметлар тудырган авазларга охшатып ясалган сүзләр







# Аваз ияртемнәрен төркемлә

- *иһа-һа-һай, бә-ә, һау-һау, эм-мә-ә, ләң-ләң, мики-ки, му-у…*
- *ка-ка-ка, кыйгак, кикрикүк, кыт-кыт-кыт, пи-би-би, бак-бак, гөлдер-гөлдер…*
- *безз-безз , чарр-чарр…*
- *чаж-пож, шарт-шорт, гөрс-гөрс, шыбыр-шыбыр, шатыр-шотыр, дырк-дырк, даң-доң, келт-келт, тырр-тырр, зырр-зырр, тик-так, гөбер-гөбер, шалт-шолт, тырр-пырр, кылтыр-кылтыр…*
- *дөп-дөп, лап-лап, шап-шап, шак-шык, лакыр-локыр, чап-чоп, тырт-тырт, тып-тып, тыз-быз, тыпыр-тыпыр, мештыр-мештер, мыштыр-мыштыр…*
- *ха-ха-ха, хи-хи-хи, үә-үә, мышык-мышык, пыш-пыш, гөж-гөж, мыдыр-медер, эһем, корык-корык, лыш-лыш, чырык-чырык …*

# Аваз ияртемнәренең төркемнәре

1. ***Хайван, җәнлек, кош-корт, бөҗәк тавышларын тасвирлый торган аваз ияртемнәре***.
2. ***Җансыз предметлар чыгарган тавышларга охшатып ясалган аваз ияртемнәре***.
3. ***Кеше хәрәкәте тудырган тавышка охшатып ясалган аваз ияртемнәре.***
4. ***Кеше тавышына охшатып ясалган аваз ияртемнәре.***

# Аваз ияртемнәре

Тавышларга охшатып ясалган аваз ияртемнәре белән бергә, кеше яки предмет хәрәкәтен, яктылык яки башка билге буенча табигать күренешен “образлы итеп күз алдына китерү өчен” дә төрле и я р т е м н ә р кулланыла. Аларны гадәттә “образ ияртемнәре” дип атыйлар



# Образ ияртемнәре

1. *Я к т ы л ы к* ***һәм*** *т ө с* ***тасвирлары:*** ***ялт, гөлт, ялт-йолт, ялтыр-йолтыр, ялык-йолык, җем-җем***
2. *Х ә р ә к ә т* ***т а с в и р л а р ы:*** ***тыр-тыр, тыз-быз, җил-җил, кәз-кәз, фырт-фырт, мелт-мелт, дерт-дерт, челт-челт, дер-дер***
3. *Э ч к е с и з е м л ә ү* ***г ә, психик халәткә бәйле тасвирлар:*** ***жу, дер-дер, дерт, леп-леп, сулк-сулык***
4. ***К ы я ф ә т һәм характер тасвирлары: фырт.***

## *Иятемнәрнең структур төзелеше*

*а) ялгызак ияртемнәр: гөрс, гөлт, дык, лып, чалт, выжт, дерт, чулт һ.б.;*

*б) парлы ияртемнәр: ялт-йолт, лаштыр-лоштыр, шак-шок, шалтыр-шолтыр, калтыр-колтыр, чыш-пыш;*

*в) кабатланып килгән ияртемнәр: дер-дер, мелт-мелт, кар-кар, кыйгак-кыйгак, тыпыр-тыпыр, кәз-кәз, җил-җил, дөбер-дөбер, шыгыр-шыгыр һ.б.;*

*г) өч компонентлы аваз ияртемнәре: ха-ха-ха, хи-хи-хи, ка-ка-ка, кыт-кыт-кыт һ.б.*

# Ияртемнәр нигезендә сүз ясалышы

Аваз һәм образ ияртемнәре нигезендә фигыльләр һәм исемнәр ясала ала.

- **Я с а л м а  ф и г ы л ь л ә р:**

а) *–ла/-лә* кушымчасы белән: *шарт**ла**, чыр**ла**, гөр**лә**, чыӊ**ла**, шау**ла**, мияу**ла** һ.б.*

б) *–а/-ә* кушымчасы белән: *шалтыр**а**, ялтыр**а**, мөгер**ә**, күкер**ә** һ.б.*

в) *–ылда/-елдә* кушымчасы белән:*чыж**ылда**, шак**ылда**, дер**елдә**, дыр**ылда**, выж**ылда**, чәр**елдә** һ.б.*

- **Тезмә фигыльләр** *ит, кил* ярдәмче фигыльләре белән ясала: *ялт ит, келт ит, шарт ит, шылт ит, ду кил, мәж кил һ.б.*
- **Исем ясалышы:** *шарлавык, гөрләвек, гөрелте һ.б.*
- Тикшеренүчеләр шулай ук аваз ияртемнәреннән морфологик аерымлану (конверсия) юлы белән яки башка ысул белән ясалган түбәндәге исемнәрне дә билгелиләр: *күке, тукран, карга, чикерткә, тукмак, йолдыз һ.б.*